

# СОХРАНЕНИЕ И РАЗВИТИЕ РОДНЫХ ЯЗЫКОВ В УСЛОВИЯХ МНОГОНАЦИОНАЛЬНОГО ГОСУДАРСТВА: ПРОБЛЕМЫ И ПЕРСПЕКТИВЫ

# КҮПМИЛЛӘТЛЕ ДӘҮЛӘТ ШАРТЛАРЫНДА ТУГАН ТЕЛЛӘРНЕ САКЛАУ ҺӘМ ҮСТЕРҮ: ПРОБЛЕМАЛАР ҺӘМ ПЕРСПЕКТИВАЛАР

памяти, забыли о сыновьем долге, превратившись потребителей. Для А. Гилязова сцена гибели героини "одна из самых главных и самых важных сцен" повести: "Здесь итог жизни Бибинур, она кончается только на такой ноте". Таков, на наш взгляд, семантических потенциал сновидения главной героини в повести А. Гилязова "В пятницу, вечером...".

**Литература**

1. Аминева В.Р. Типы диалогических отношений между национальными литературами (на материале произведений русских писателей второй половины XIX в. и татарских прозаиков первой трети XX в.). – Казань: Казан. гос. ун-т, 2010. – 476 с.

2. Архив писателя: «Җомга көн, кич белән...» (вариант №3) (объем – 93 с.).

3. Гыйләҗев А. Әсәрләр дүрт томда. -- 3 т. Повестьлар, роман. – Казан: Тат. китап. нәшр., 1994. – 567 б.

4. Гилязов А. При свете зарниц. Повести. / Переводы с татарского. – М. Сов. Россия, 1990. – 496 с.

5. Ибрагимов М. Мифопоэтический анализ текста (на примере повести А. Гилязова "Җомга көн, кич белән") Ибрагимов М. Миф в татарской литературе XX века: проблемы поэтики. – Казань: Gumanitaria, 2003. – С.14-31.

6. Топоров В.Н. Странный Тургенев: (Четыре главы) / В.Н. Топоров – М.: Рос. гос. гуманит. ун-т, 1998. – 192 с.

## ТАТАРСТАННЫҢ ИСЛАМ ДИНЕ ТЕРМИННАРЫНА НИСБӘТЛЕ ТОПОНИМНАРЫ[30]

Г.К. Һадиева

Казан федераль университеты, Казан

Халыкның тарихын, яшәү шартларын белмичә, телне тулысынча аңлап булмый. Татар телендә дөньяның милли картинасы мәҗүсилек һәм меңьеллык ислам дине традицияләренең синтезлануы белән үзенчәлекле. Башка диннәрдән аермалы буларак, ислам дине кешенең яшәү рәвешенә, дөньяны кабул итүенә йогынты ясый. Бу йогынты телдә дә чагылыш таба һәм без аны топонимик системада да күрәбез.

Мәҗүсилектән ислам диненә күчү Идел буе Болгар дәүләтенең халыкара абруен, дәрәҗәсен күтәргән, төрле мәҗүси йолалар тотучы болгар кабиләләрен бер югары дәүләт хакимияте тирәсенә туплаган, дәүләтнең һәм халыкның рухи тормышының хокукый-әхлакый кануннарының, мәдәни үсеше, культура идеологиясенең нигез ташын тәшкил иткән. Ислам дине кеше исемнәре һәм географик атамалар хәзинәсенең баю-тулылануына зур роль уйный, татар антропонимиясенең һәм топонимиясенең тарихи күчемлелеген, эзлекле үсү-камилләшүен, ономастик мирасын тәэмин итә [8, 327].

Гарәп-фарсы алынмалары телебездә зур урын алып торалар. Бу алынмалар, Болгарда ислам дине кабул ителгәннән соң, сәүдә, дин, сәясәт, мәдәният, әдәбият-сәнгать бәйләнешләре аша килеп кергәннәр. Дини терминнарга нисбәтле географик атамаларның күпчелеге борынгы заманнарда ук барлыкка килгәннәр.

Топонимиядә иң еш кулланыла торган дини терминнарның берсе – *мулла* рухани титулы. Элек-электән татар авылларында мулла ислам диненең йолаларын үтәүче генә түгел, ә авылны оештырып, бергә туплап торучы үзенә күрә бер "җитәкче" булып саналган. Аның киңәшләренә һәрвакыт колак салганнар. Мулланың үз чәчүлек җирләре һәм болыннары булган. Тора-бара бу җирләр мулла җирләре булудан туктаса да, атама сакланып калган һәм безнең көннәргә килеп җиткән. Мулла – Урта Азия (үзбәк, таҗик) телләрендәге "мулла" сүзеннән, гарәп телендә "мәүлә", ягъни "күп укыган, күкрәге гыйлем белән тулы" сүзеннән килә дип санала. [1, 147]. Мулла сүзе күп микротопонимнар ясалышында катнаша. Мәсәлән, *Мулла чалуы* (Буа р-ны, Каенлык авылы) – авыл зурая башлагач мулла кирәк булган. Хезмәте өчен тәрбияләргә риза булып, авыл халкы муллага егерме сутый чалу биргән. Чалу бу очракта, эшкәртү өчен бирелгән җир мәгънәсендә. Сарман районындагы *Мулла чалуы* дигән микротопоним – көннең эссе вакытында су буенда туктап ял итә торган урынны да белдерә; *Мулла зираты басуы* – авыл кырыендагы зиратка мулла күмелгән. Хәзер шул урында басу, шуңа *Мулла зираты басуы* (Азнакай р-ны Кәкре Елга авылы) дип йөртелә. *Мулла үзәне* – авылның көнбатышындагы һәм көнчыгышындагы ике уйсу үзәнлек. Электән бу ике үзән сөрелмичә, анда печән үстерелгән. Бу үзәнлек авыл мулласыныкы булган. Шуның өчен *Мулла үзәне* (Кукмара р-ны Ядегәр авылы) дип атала; *Мулла куаклыгы* (Балтач р-ны Арбор авылы) – бу урында үскән куакларны авыл мулласы утырткан. *Мулла чабындысы* – ачык җирдә урнашкан печән үсә торган болын (Ютазы р-ны Бәйрәкә авылы); *Мулла чишмәсе* (Әлки р-ны Карамалы авылы, Балтач р-ны Көек авылы, Балык Бистәсе р-ны Яңа Арыш авылы); *Мулла печәнлеге* (Арча р-ны Күпербаш авылы); *Мулла елгасы* (Арча р-ны Иске Ашыт авылы, Саба р-ны Яңа Мичән авылы, Балтач р-ны Көек авылы, Аксубай р-ны Үзи авылы); *Мулла сазы* (Саба р-ны Яңа Мичән авылы, Кайбыч р-ны Урсак авылы); *Мулла болыны* (Сарман р-ны Иске Минзәләбаш авылы); *Мулла аланы* (Яшел Үзән р-ны Мамадыш-Әкил авылы); *Мулла ышнасы* – урман эчендә

[30] Статья выполнена в рамках исследовательского проекта № 12-14-16032а/В/2012 (РГНФ)

чү өч н печ ч о алу өчен а хуҗалыкларга бүлеп и лгән алан (Апас р-ны Мазиково авылы); *Мулла тавы* (Яшел Үзән р-ны Олы Ачасыр авылы). Яшел Үзән районындагы *Мулла Иле* авылының исеме *Муллагол* дигән борынгы болгар кешесе исеме белән мөнәсәбәтле, *Муллагол* исеме элек сословие терминнары булган *мулла* һәм *гол/кол* сүзләреннән тора. Татар теленә гарәп теленнән кергән *мулла* сүзе рухани сан төшенчәсен генә белдермәгән, "укымышлы, белемле кеше, гыйлем иясе" мәгънәсендә дә кулланылган һәм борынгы кеше исемнәре составында шактый еш урын алган. Мәсәлән, *Муллабай, Муллагали, Мулланур, Бикмулла* һ.б. Борынгы кеше исемнәре составында шулай ук еш очрый торган *кол/гол* сословие титулы шәхеснең чыгышы ягыннан кол булуын билгеләүдән тыш, аның "алла колы, алла бәндәсе" булуын да белдергән: *Рахманкол, Собханкол, Мәүләкол* һ.б. [7, 159].

*Шәех* – мөселман рухи иерархиясендә югары дәрәҗә, ягъни дин башлыгы [1, 17]. Әлеге термин белән Арча районындагы *Хәсәншәех* авылы барлыкка килгән. Аксакаллар сөйләвенә караганда, элекке заманнарда бу якка *Хәсәншәех* исемле изге кеше килеп чыккан һәм шушында яшәп калган, авылга нигез салган. *Хәсән* – аның исеме, *шәех* – дәрәҗәсе булган, ягъни *Хәсән хәзрәт* дигән мәгънә аңлаткан. *Хәсән* – "яхшы, игелекле, матур, күркәм" дигән мәгънәне аңлата. Авылга шуңа бәйле, *Хәсәншәех* атамасы бирелгән.

*Мәзин* – мөселман рухи иерархиясенең шәехтән соң торучы дин башлыгы. Әлеге термин белән түбәндәге атамалар ясалган: *Мәзин күле* (Кама Тамагы р-ны Бәки авылы); *Мәзин елгасы* (Балтач р-ны Бөрбаш авылы, Арча р-ны Җөлби авылы).

*Мәчет* – мөселманнарның гыйбадәт кылу, гөнаһларын ярлыкау урыны. Әлеге лексема белән түбәндәге атамалар барлыкка килгән: *Мәчет елгасы чишмәсе* (Чирмешән р-ны Иске Кади авылы); *Мәчет тавы* (Өтнә р-ны Дусым авылы); (Кама Тамагы р-ны Бәки авылы), *Мәчет урамы* (Кама Тамагы р-ны Барыш авылы); *Мәчет күле* (Яшел Үзән р-ны Мамадыш-Әкил авылы); *Мәчет күпере* (Балык Бистәсе р-ны Олы Елга авылы).

*Корбан* "жертва" – гарәп телендә курбан-ун "корбан" сүзеннән [1, 112]. Ут белән су Тәңре тарафыннан җибәрелгән бүләк. Хәтта "Ут белән су Алла кулында" дигән татар мәкале бар. Ә борынгылар утка, суга табынганнар. Алар елга янына җыелып корбан китергәннәр. Шушы йолага бәйле, Чүпрәле районында *Корбан елгасы* дигән атама барлыкка килгән [3, 56].

*Дәрвиш* "доньядан ваз кичкән диндар кеше, аскет", фарсы чыгышлы термин. Әлеге лексема белән Әлки районы Әхмәт авылында *Дәрвиш чокыры* һәм Казан шәһәре янында *Дәрвишләр бистәсе* дигән атамалар ясалган.

*Намаз* "намаз, молитва" – фарсы теленнән намаз сүзеннән "баш иеп сәламләү". Намаз гамәле ислам диненә ирани халыклардан кергән [1, 49]. Әлеге термин белән Татарстанда Биектау районы Әйшә авылында *Намаз укый торган урын* дигән изге тау атамасы барлыкка килгән.

*Гает* – мөселманнарда ураза һәм корбан бәйрәмнәрендә башкарыла торган махсус гыйбадәт – намаз исеме, гарәп теленнән кергән. *Гает кизләве* – чишмә атамасы (Чүпрәле р-ны Иске Чынлы авылы).

*Нәзер* "адарыну". Нәзер термины белән *Нәзер болыны* (Арча р-ны Түбән Оры авылы), *Нәзер күле* (Кайбыч р-ны Яңа Буа авылы), *Нәзер чокыры* (Лениногорск р-ны Сарабиккол авылы) атамалары барлыкка килгән.

*Сәдака* – татарларда дини йолаларны үтәү йөзеннән руханиларга бирелә торган хәер, гарәби чыгышлы сүз. *Сәдака урамы* (Чирмешән р-ны Елховой авылы).

*Ураза* "ураза, мусульманский пост". Нугай, казах, каракалпак телләрендә *ораза*, борынгы татар, чыгытай телләрендә *руза* "ураза көне" фарсы телендәге "көн" сүзеннән [1, 220]. *Ураза елгасы* (Биектау р-ны Зур Көек авылы), *Ураза чишмәсе* (Әлмәт р-ны Миңлебай авылы) дигән атамалар барлыкка килгән.

*Әүлия* "изге кеше, "алдан күрүче, күрәзәче, терелтүче". Элек-электән кешеләр үзләре арасында чиста, саф күңелле, изге гамәлләр кылган кешене аерып куйганнар. Бу кешене изгеләштергәннәр, аңарга табынганнар. Шушы йолага бәйле рәвештә төрле микротопонимнар барлыкка килгән. Мәсәлән, *Әүлия кабере* турында өлкән буын түбәндәгеләрне сөйли: авылның көньяк юнәлешендә биек булып торган урында ике кабер бар. Халык аны *Әүлия кабере* дип атый. Бу изгеләрнең исемнәрен Вәхшандияр һәм Искәндаяр дип әйтәләр. Шул каберлекләр каршына йорт салынган. Бу йорт изге урын булып исәпләнә (Биектау р-ны Сая авылы); *Әүлия кабере* (Лаеш р-ны Яушык авылы, Мөслим р-ны Бүләк авылы, Биектау р-ны Әлдермеш авылы); *Әүлия чишмәсе* (Актаныш р-ны Байсар авылы, Әтнә р-ны Мөндеш авылы); *Әүлия зираты* (Кукмара р-ны).

Башкортстанның Бәләбәй районы Иске Турай авылында *Әүлия тавы* дигән тау бар. Башкортлар хөрмәткә лаек кешеләрне тауга күмгәннәр, бу кешеләрне изгеләштергәннәр [2, 98].

*Изге* сүзе “святой” борынгы төрки *әд + гу* “изге” сүзеннән, борынгы Орхон язмаларында *әд* “байлык, яхшылык” дигән мәгънәдә кулланылган. Бу сүз гарәп теленнән кергән *әулия* сүзе белән синонимдаш.

Ислам дине үзенә хас изгеләр культын тудырган. Коръәндәге изгеләрдән тыш, ислам динен таратучылар, суфилар, башка диндәге халыклар белән сугышта һәлак булган шәһидләр изгеләштерелгән. Болгар патшасы гаиләсен төрле тылсымга ия булган дин таратып йөрүче бер изге кеше терелтә. Шуннан соң патша һәм аңа буйсынган халык ислам динен кабул итә. Хәзер күп кенә *изгеләр кабере*, *изгеләр чишмәсе* дигән урыннар халкыбыз тарафыннан ихтирам ителә. Бу урыннар, нигездә, болгар археологик истәлекләре белән бәйләнгәннәр [4, 55].

Биләр янындагы *Хуҗалар тавы* астындагы *Изгеләр чишмәсе* һәм тау өстендәге *Изгеләр күмелгән җир* элек-электән үзенә күрә хаҗ урынына әверелгән. Биләр чишмәсенә хәтта монда узган гасырда да ерак Урта Азиядән ишәккә атланып изге җирләргә баш иярга килгәннәр дип сөйлиләр. Мондый урыннар хәзер дә татар, рус, чуашлар тарафыннан хөрмәт ителәләр. Төрле милләт һәм дин вәкилләренең берүк урынны шулай тирән изгеләштерүләре борынгылыктан ук бу җирнең мәҗүси гыйбадәтханә булуы хакында сөйли.

Татарлар, *изге* дип ислам диненә, Аллага бөтен гомерләрен, эш-шөгыльләрен багышлаган үтә диндар кешеләрне атыйлар. Балык Бистәсе районы Балыклы Чүкәй авылында ел саен июнь башында жомга көн – *Изгеләр бәйрәме* үткәрелә. Һәр кеше ашау ризыгы бирә. Бу әйберләр белән аш пешерәләр. Башта жомга намазы укылган, аннан ризык өләшенгән. Халык дога кылып. өйләренә таралышкан. Хәзер бу бәйрәм яңгыр сорау йоласына тоташа. Изге термины белән түбәндәге атамалар барлыкка килгән. Мәсәлән, *Изге зират, Изге зират күпере* (Саба р-ны Байлар Сабасы авылы); Саба районы Кече Мирәтәк авылының *Изгеләр зираты* дип йөртелә торган каберлеге *Зөлката* исемен йөртә. *Зөлката* гарәпчә *зел* “иясе бар” + *ката* “кальга” мәгънәсендә. [5 115]. Зөлката эчендәге каберлекләр өстендә борынгы язулы ташлар бар. Авыл аксакаллары борынгы заманнарда бу тирәләрдә каты сугышлар булган диләр; *Изгеләр чишмәсе* (Кукмара р-ны Янсыбы авылы, Балык Бистәсе р-ны Балтач авылы, Аксубай р-ны Иске Кармәт авылы, Балтач р-ны Иске Салавыч авылы, Яшел Үзән р-ны Олы Җәке авылы); *Изге чишмә* (Арча р-ны Хәсәншәех авылы, Балык Бистәсе р-ны Яңа Арыш авылы); *Изгеләр чокыры* (Мөслим р-ны ); *Изгеләр суы* (Кама Тамагы р-ны Иске Барыш авылы); *Изгеләр зираты тавы* (Яшел Үзән р-ны Күгәй авылы); *Изгеләр коесы* (Питрәч р-ны Күн авылы); *Изгеләр урыны* – урын атамасы (Чирмешән р-ны Иске Үтәмеш авылы ); *Изге кабер өсте* – кыр атамасы (Чувашстанның Комсомольск р-ны Урамай авылы).

*Әҗәл* – “смертный час” – гарәп телендә *әҗәл-ун* “срок, аралык, гомер срогы” сүзеннән. Чуваш диалектында *ичел*, мариларда *азал*, удмуртларда *эзель* [1, 26]. Бу микротопоним, күбесенчә. үлем-китем еш булган урыннарга карата әйтелә. Мондый урыннар кешеләрне шомландыра. Мәсәлән, *Әҗәл елгасы* (Теләче р-ны Олы Мәтәскә авылы); *Әҗәл куле* (Биектау р-ны Кече Рәс авылы); *Әҗәл басуы* (Кукмара р-ны Ядегәр авылы).

*Зират* – гарәп теленнән “күрергә, күрешергә бару урыны”. Татар телендә *зират* төшенчәсен белдерү өчен *каберлек, мазар* терминнары кулланыла. Болгар-татар теленә *мазар* сүзе гарәп теленнән кергән. Ул “бару урыны” дигәнне аңлата [9, 155]. Татарстан топонимиясендә *мазар* терминына нигезләнеп Биектау районындагы *Мазар* дигән татар авылының исеме ясалган; *Мазар әрәмәсе* (Буа р-ны Боерган авылы); *Иске Чирмеш каберлеге* – басу исеме (Актаныш р-ны); *Иске каберлек* (Чүпрәле р-ны Яңа Кәкреле авылы); *Иске зират басуы* (Мөслим р-ны Яңа Сәет авылы); *Зират асты басуы* (Яшел Үзән р-ны Мулла Иле авылы ); *Өч агачлы зират* – зират исеме (Арча р-ны Кызылъяр авылы ); *Яхшылар зираты* (Кама Тамагы р-ны Карамалы авылы ); *Зират тавы* ( Балтач р-ны Каракүл авылы); *Зират асты болыны* (Балтач р-ны Каракүл авылы).

Идел-Кама болгарларында, чувашларда һәм керәшен татарларында кешенең үлүенә бер ел тулгач, аны искә алып, еллыгын үткәрү, каберенә багана утырту йоласы башкарылган. Бу көн “Багана бәйрәме” дип аталган. Шушы йоланы башкару Татарстанның Әлмәт районы Сарапалы авылы керәшеннәрендә күзәтелә. Багана ойконимик терминына мөнәсәбәтле рәвештә Татарстанның Чистай районында *Татар Баганасы* һәм *Багана* авылларының исемнәре барлыкка килгән.[1]

*Җомга көн* изге көн культы белән бәйләнешле, Арча районындагы *Бәрәскә авылы* атамасы барлыкка килгән. Грек телендә *параски* “жомга көн” мәгънәсен белдерә. Бу көн мөселманнарның мәчеткә барып, гөнаһларын юуу, сәдака бирү көне. Авылга атама шушы йолага нисбәтле бирелгән [5, 154].

... борынгы заманнардан башлап, кешенең үзе ... алган табигать-мохит белән турыдан туры бәйләнешкә керүе, аралашуы нәтиҗәсендә пәйда булган. Татар теленең җирле географик терминологиясен һәм топонимисен формалаштыруда гарәп-фарсы алынмаларының актив булуы ачыкланды. Шушы алынмаларга нигезләнеп ислам диненә нисбәтле географик атамалар барлыкка килгәннәр. Бүгенге көндә алар киң таралыш алган. Халык өчен иң мөһиме, алынмаларның борынгыдан килеп, безнең гореф-гадәтләребезне чагылдыруы.

### Әдәбият


1. Әхмәтьянов Р.Г. Татар теленең кыскача тарихи-этимологик сүзлеге. – Казан: Тат. кит. нәшр., 2001. – 272 б.
2. Бухарова Г.Х. Башкирская ономастика в контексте духовной культуры: Словарь мифотопонимов. – Уфа: Гилем, 2006. – 116 с.
3. Давлетшин Г.Г. Очерки по истории духовной культуры предков татарского народа. – Казань: Тат. кн. из-до, 2004. – 429 с.
4. Дәүләтшин Г. Төрки-татар рухи мәдәнияте тарихы. – Казан: Тат. кит. нәшр., 1999. – 512 б.
5. Саттаров Г.Ф. Атамалар дөньясына сәяхәт. – Казан: Тат. кит. нәшр., 1992.
6. Саттаров Г.Ф. Исемең матур, кемнәр куйган? – Казан: Тат. кит. нәшр., 1989. – 256 с.
7. Саттаров Г.Ф. Мәктәптә туган як ономастикасы. – Казан: Тат. кит. нәшр., 1984. – 208 б.
8. Саттаров Г.Ф. Татар топонимиясе. – Казан: Казан ун-ты нәшр-ты, 1998. – 438 с.
9. Татар теленең аңлатмалы сүзлеге: 2 томда. 2 том. – Казан: Тат.кит.нәшр., 1993.


## ДИСКУРСИВНЫЙ АНАЛИЗ ПРОИЗВЕДЕНИЯ М.МАГДЕЕВА «ЛЕБЕДИНАЯ ПЕСНЯ»


Хадиева Э.Р.

Казан федераль университеты магистры


Дискурс – (фр. discours, от лат. discursus — рассуждение, довод) один из самых многозначительных терминов, используемых современной лингвистикой, семиотикой, философией. Под этим словом в первую очередь понимают организацию системы речи, через которую осуществляется предметный анализ объекта. В то же время дискурс – это непосредственно сама речь, обусловленная влияющими на нее внешними факторами.

Дискурс может являться объектом изучения для многих наук. Так на пример, через дискурс пациента психология анализирует его состояние. Но литературоведение же через дискурс героев литературных текстов анализирует само произведение, идею и основную мысль автора, позиции. Таким образом, дискурс может являться объектом разных наук, но цели и предметы изучения при этом будут различны.

В структурализме и нарротологии же дискурсу отводятся одни из ключевых мест."Дискурс интерпретируется как семиотический процесс, реализующийся в различных видах дискурсивных практик. Когда говорят о дискурсе, то в первую очередь имеют в виду специфический способ или специфические правила организации речевой деятельности (письменной или устной) «...» В нарратологии проводят различие между дискурсивными уровнями, на которых действуют повествовательные инстанции письменно зафиксированные в тексте произведения: эксплицитный автор, эксплицитный читатель, персонажи-рассказчики и т. д., и абстрактно-коммуникативными уровнями, на которых взаимодействуют имплицитный автор, имплицитный читатель, нарратор в "безличном повествовании" (нарративная типология)".[31]

Дискурсивный анализ – это исследование построения дискурса, понимания дискурса адресатом (читателем), рассмотрение позиций и особенностей языкового общения в конкретном тексте.[32]

В данной научной работе мы попытаемся рассмотреть рассказ Мухаммата Магдеева «Лебединая песня» в рамках дискурсивного анализа.

Начнем с первого элемента произведения – его названия. Часто оно является ключом к основному смыслу литературного текста. Бывает и так, что он несет в себе символ или ряд символов, созвучных с основной канвой текста. В данном же случае название «Лебединая песня» не является символом. Скорее всего он выступит в качестве ключа к основной части произведения. Об этом свидетельствует и следующий далее элемент рассказа – первая часть текста.

Структура «Лебединой песни» очень своеобразна своим строением. Текст произведения разделен на две отдельный тематические части. Первая часть не выступает ни в роле самостоятельного рассказа, ни в роле эпиграфа и даже не является прологом произведения. Он напрямую связан с названием и отделен расстоянием от канвы основного текста: «Лебеди,

---

[31] И. П. Ильин. Словарь постмодернизма. – М.: Интрада, 2001. – с.76-77
[32] http://studentbank.ru/view:php?id=32541&p=7